СОВЕТ НОРМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
НОРМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«5» июль 2018 ел № 91

«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлегенең 2018 елга һәм 2019-2020 еллар план чорына бюджеты турында» 2017 елның 26 декабрендәге 72 номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советының карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге баш хисапчысы А.П. Таҗиеваның Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында мәгълүматын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлегенең 2018 елга һәм 2019-2020 еллар план чорына бюджеты турында» 2017 елның 26 декабрендәге 72 номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советының карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. 2018 елга Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга.

1) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге бюджетының фаразлана торган керемнәренең гомуми күләмен 11861236,33 сум итеп;

2) Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 11951233,33 сум итеп;

3) Балтач муниципаль районының Норма авыл җирлеге бюджетының 89997 сум күләмендәге кытлыгы 2017 елның калган акчасы хисабына капланды.

Өстәмә пунктлар кертергә:

4) бюджет керемнәре күләмен арттыруны 1393400 сум күләмендә гражданнардан кергән үзара салым акчалары исәбенә, 5726900 сум күләмендә бюджетара трансфертлар исәбенә һәм 510000 сум күләмендә дотация исәбенә башкарырга.

5) бюджет чыгымнарын арттыруны түбәндәге статьялар буенча башкарырга: югары вазыйфаи затның (башлыкның) эшләвенә 85700 сум, юл хуҗалыгы 5910600 сум, җирләү урыннарын оештыру һәм карап тоту 235000 сум, башка төзекләндерүләр 1349000 сум, социаль ярдәм чараларын тәэмин итү 50000 сум.

2. 1 нче, 3 нче, 8 нче, 10 нчы кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә».

Рәислек итүче
Норма авыл җирлеге Советы Депутаты С. М. Исрафилов